СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2024 г. Агрыз № 40-1

# Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлегенең Комсомолка поселогын бетерү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 07.12.2005 елның 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 7 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Комсомолка поселогын бетерергә.
2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Комсомолкасы поселогын бетерү һәм «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән закон проектын караганда Әгерҗе муниципаль районы Советы вәкиле итеп Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы урынбасары Ямалиев Илфат Ильяс улын билгеләргә.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе урынбасары,
Муниципаль район Башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев